БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 июль 2024ел № 265

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Яңгул авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге территориясенең шәһәр төзелешен планлаштыруны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15 статьяларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, гавами тыңлаулар һәм килештерү комиссиясе нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Яңгул авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге башкарма комитетына:

- шәһәр төзелеше эшчәнлеген әлеге карарның 1пункты белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы “Яңгул авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырырга;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Яңгул авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турындагы карарын территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасына йөкләүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Балтач муниципаль район башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н.Сабирҗанов